**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1077**
**05.03.2020**

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2019 елның 27 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 29 ноябрендәге 7122 номерлы карары (Башкарма комитетның 2019 елның 19 августындагы 4267 номерлы карары редакциясендә) белән эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль Законның (алга таба – 44 номерлы Закон) 99 статьясының 27 бүлеге нигезендә контроль органының вазыйфаи заты түбәндәге хокукларга ия:»

2) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Сатып алулар өлкәсендә контроль эшчәнлеге түбәндәгеләргә карата гамәлгә ашырыла (сатып алулар өлкәсендә контроль предметы):

1) 44 номерлы Законның 19 статьясы нигезендә билгеләнгән сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру кагыйдәләрен үтәү;

2) бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелгән контракт бәясен, контрактның башлангыч (максималь) бәясен, товар, эш, хезмәт берәмлегенең башлангыч бәясен,  товар, эш, хезмәт берәмлеге бәяләренең башлангыч суммасын билгеләү һәм нигезләү;

3) контрактны үтәүгә, үзгәртүгә карата 44 номерлы Законда каралган таләпләрне үтәү, шулай ук контракт шартларын үтәү, шул исәптән кайтарылган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсенең) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килүе өлешендә;

4) кайтарылган товардан, башкарылган эштән (аның нәтиҗәсеннән) яки күрсәтелгән хезмәттән файдалануның сатып алуны гамәлгә ашыру максатларына туры килүе.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев